**МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кремлевская ул., д. 9; Казань, 420111
Тел.: (843) 292-92-12; тел./факс: 292-93-51
E-mail: mon@tatar.ru http://www.mon.tatar.ru
ОКПО 00099837, ОГРН 1021602833196
ИНН/КПП 1654002248 / 165501001

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ**

Кремль урамы, 9 нчы йорт, Казан шәһәре, 420111,
Тел.: (843) 292-92-12; тел./факс: 292-93-51
E-mail: mon@tatar.ru http://www.mon.tatar.ru
ОКПО 00099837, ОГРН 1021602833196
ИНН/КПП 1654002248 / 165501001

Татарстан Республикасы
муниципаль районнары
башкарма комитетларының мәгариф
идарәләре һәм бүлекләре җитәкчеләренә

ММУ хезмәткәрләренә

Федераль дәүләт белем стандартлары нигезендә мәктәпләрдә татар телен һәм әдәбиятын укыту турында

**Хөрмәтле коллегалар!**

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы 2014/2015 нче уку елында гомуми белем бирү мәктәпләрендә «Татар теле» һәм «Әдәбият» фәннәре буенча төзелгән үрнәк программалар, дәреслекләр турында һәм аларны куллану буенча түбәндәге аңлатманы җибәрә.

Россия Федерациясе мәгариф һәм фән министрлыгы боерыклары белән гомуми белем бирүнең өч федераль дәүләт мәгариф стандарты (башлангыч гомуми белем бирү – № 373, 06.10.2009 ел; төп гомуми белем бирү – № 1897, 17.12.2010 ел; урта (тулы) гомуми белем бирү – № 413, 17.05.2012 ел) расланды.

Гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем стандартлары (алга таба – ФДБС) мәгариф системасына баскычлап кертелә. Башлангыч гомуми белем бирү баскычында ФДБС 2011/2012 уку елыннан кулланыла башлады. Ә төп гомуми белем бирү баскычында яңа буын ФДБС-на күчү 2015/2016 уку елыннан, урта (тулы) гомуми белем бирү баскычында - 2020/2021 уку елыннан тормышка ашырылачак.

Татарстан Республикасы гомуми белем бирү мәктәпләрендә «Татар теле», «Әдәбият» («Әдәби уку») фәннәрен укыту башлангыч, төп һәм урта гомуми белем бирү оешмалары өчен төзелгән базис һәм үрнәк уку-укыту планнары (Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының 2012 елның 9 нчы июлендә гамәлгә кертелгән 4154/12 санлы, 2012 елның 10 нчы июлендә гамәлгә кертелгән 4165/12 санлы боерыклары) һәм Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының 9777/12 санлы (13.08.2012 ел), 9127/13 санлы (09.07.2013 ел) хатлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан V-XI сыйныфлар өчен «Татар теле», «Әдәбият» фәннәре буенча, ФДБС-на нигезләнеп, өч юнәлештәге (татар телендә төп һәм урта гомуми белем бирүче мәктәпләр, рус телендә төп һәм урта гомуми белем бирүче мәктәпләрнең татар төркемнәре һәм рус телендә сөйләшүче балалар төркемнәре өчен) үрнәк программалар әзерләнде һәм агымдагы елның 24 февралендә 933/14нче боерык белән расланды. Үрнәк программалар татар һәм рус телләрендә Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы сайтына урнаштырылды: mon.tatarstan.ru/, национальное образование,/ программы по татарскому языку и литературе/.

Яңа үрнәк программалар буенча укыту ФДБС-на күчү белән турыдан-туры бәйләнгән. 2014/2015 уку елына, үрнәк программаларга нигезләнеп, V – VII сыйныфлар өчен татар теле һәм әдәбияты дәреслекләре әзерләнде, һәм мәктәп яңа ФДБС-на күчк



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

дәреслекләр белән эшли башларга мөмкин. (Беркетмәне карагыз.) Моңа кадәр гамәлдә булган дәреслекләрдәге материалны укытучы шулай ук гамәлдәге авторлык программаларына яисә яңа үрнәк программаларга нигезләнеп куллана ала. Үрнәк программаларга кертелгән материал һәм әсәрләр өйрәнү өчен мәҗбүри, а калган материалны укытучы, сыйныфтагы укучыларның психологик һәм физиологик үзенчәлекләреннән чыгып, иҗади файдалана. Укучыларның белемнәрен тикшерү өчен материаллар әлеге үрнәк программаларда күрсәтелгән планлаштырыла торган нәтиҗәләргә таянып төзеләчәк.

Яңа ФДБС IX сыйныфны төп белем бирү баскычын тәмамлау сыйныфы буларак карый. IX сыйныфны тәмамлаганнан соң балалар X-XI сыйныфка күчә яки һөнәри белем бирүче уку йортларына китә ала. Гамәлдәге программаларда һәм дәреслекләрдә исә IX сыйныфта әдәбият тарихыннан 3 елга (IX-XI сыйныфлар) бүленгән курсның беренче елда бирелә торган материалы гына өйрәнелә. Шуңа күрә, IX сыйныфны тәмамлап мәктәптән китүче балаларның әдәбият тарихыннан белемнәре XIX гасыр уртасында өзелә, аеруча мөһим чор – XX гасыр һәм хәзерге әдәбият бөтенләй исәпкә алынмый. Шул сәбәпле, үрнәк программаларда IX сыйныфка кадәр үтелә торган материал төп белем бирү баскычын йомгакларлык итеп сайланган.

IX сыйныфта тулы курс төгәлләнгәннән соң, укучылар X-XI сыйныфларда кабат әдәбият тарихына хронологик тәртиптә әйләнеп кайтып, белемнәрен тулыландыралар. Гамәлдәге дәреслекләрдә 1920-30 еллар татар әдәбиятына бәянең тулы түгеллеген исәпкә алып, әдәби материалның яңаруы заман таләбе белән аңлатыла. Гамәлдәге дәреслекләрдә "Хәзерге әдәбият" бүлекчәсе астында бирелә торган әсәрләрнең 1960-70 елларга каравы билгеле. Яңа үрнәк программаларда хәзерге әдәбият XX гасыр ахырын (1980-2000) һәм XX1 гасыр әдәбиятын үз эченә ала.

Яңа үрнәк программаларга кергән, гамәлдәге дәреслекләрдә булмаган әсәрләр мәктәп китапханәләрендә төрле җыентыкларда бар, күбесен интернет челтәрендә электрон форматта табарга мөмкин.

Шулай итеп, укытучылар үзләренең V-IX һәм X-XI сыйныфлар өчен эш программаларын яңа үрнәк программаларга, авторлык программаларына һәм дәреслекләргә яки гамәлдәге авторлык программаларына һәм дәреслекләргә таянып, төбәкнең ихтыяҗларын, мәктәпнең белем бирү программасы үзенчәлекләрен һәм балаларның әзерлек дәрәҗәсен, шәхси мөмкинлекләрен исәпкә алып төзиләр. Мәҗбүри шарт: үрнәк программалардагы материал һәм әсәрләр һәр укытучының эш программасында сакланырга тиеш. Уку материалын өйрәнүгә сәгатьләр саны бүленешендә, материалны өйрәнү эзлеклелеген билгеләүдә һәм эчтәлекне киңәйтүдә укытучылар тарафыннан үзгәрешләр кертелергә мөмкин. Бу үзгәрешләр эш программаларының аңлатма язуында чагылыш табу шарт.

ФДБС-нда урнаштырылган таләпләр гомуми белем бирүнең барлык баскычларында укытуның яңа ысулларын, нәтиҗәле укыту технологияләрен куллануны таләп итә. Рус төркемнәрендә татар теле һәм әдәбияты укытуның сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген күтәрү максатыннан белем бирү процессы коммуникатив технологияләргә нигезләнеп оештырылырга тиеш. Сыйныф журналларында «Татар теле», «Әдәбият» («Әдәби уку») фәннәре аерым языла.

2014/2015 уку елында гамәлдәге авторлык программалары белән эшләү тыелмый. Бу очракта белем бирү гамәлдәге дәреслекләрне кулланып башкарыла.

Министр урынбасары
вазифаларын башкаручы И.Р.Мөхәммәтов

## Для образовательных организаций с русским языком обучения
## Для русскоязычных учащихся

1. Мотигуллина А.Р., Ханнанов Р.Г., Хисматова Л.К., **Әдәбият, 5 кл.**
2. Мотигуллина А.Р., Ханнанов Р.Г., Гизатуллина Э.Х., **Әдәбият, 6 кл.**
3. Мотигуллина А.Р., Ханнанов Р.Г., Мулласалихова Г.Г., **Әдәбият, 7 кл**

1. Фатхуллова К.С., **Татар теле, 5 кл.**
2. Фатхуллова К.С., **Татар теле, 6 кл.**
3. Фатхуллова К.С., **Татар теле, 7 кл.**

1. Хайдарова Р. З. и др., **Татар теле, 5 кл.**
2. Хайдарова Р. З. и др., **Татар теле, 6 кл.**
3. Хайдарова Р. З. и др., **Татар теле, 7 кл.**

1. Нигматуллина Р.Р., **Татар теле, 5 кл.**
2. Нигматуллина Р.Р., **Татар теле, 6 кл.**
3. Нигматуллина Р.Р., **Татар теле, 7 кл.**

## Для образовательных организаций с русским языком обучения
## Для учащихся татар

1. Хасанова Ф.Ф., Сафиуллина Г.М., Гарифуллина М.Я., **Әдәбият, 5 кл.**
2. Хасанова Ф.Ф., Сафиуллина Г.М., Гарифуллина М.Я., **Әдәбият, 6 кл.**
3. Хасанова Ф.Ф., Сафиуллина Г.М., Гарифуллина М.Я., **Әдәбият, 7 кл.**

Идут в комплекте с действующими учебниками по татарскому языку.

## Для образовательных организаций с татарским языком обучения

1. Ганиева Ф.А., Сабирова Л.Г., **Әдәбият, 5 кл**

Идут в комплекте с действующими учебниками по татарскому языку, 2012 год

2. Ганиева Ф.А., Гарифуллина М.Д., **Әдәбият, 6 кл**

Юсупов Ф.Ю., Харисова Ч.М., Сайфетдинов Р.Р., **Татар теле, 6 кл**

3. Абдуллина Д.М., Хисматова Л.К., Завгарова Ф.Х., **Әдәбият, 7 кл**

Максимов Н.В., Набиуллина Г.А., **Татар теле, 7 кл**